СОВЕТ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** с.Старое Дрожжаное **КАРАР**

2023 елның 9 ноябре № 32/4

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турында нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Уставының 29 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советының 2019 елның 23 октябрендәге 38/1 номерлы (27.05.2021 № 9/4, 16.03.2022 № 18/8, 31.05.2022 № 19/4, 13.02.2023 № 25/1, 17.08.2023 № 30/2 номерлы карарлар редакциясендә) карары белән расланган Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында бюджет корылышы һәм бюджет процессы турындагы Нигезләмәгә 22 статьяны түбәндәге яңа редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

**«22 статья. Район Советы тарафыннан бюджет турында карар проектын карау**

Районның чираттагы финанс елына һәм планлы чорга бюджеты турында карар проекты кертелгәннән соң бер тәүлек эчендә район Башлыгы аны район контроль-хисап палатасына экспертиза үткәрү өчен җибәрә. Бюджет проекты шулай ук рәсми рәвештә бастырылырга һәм гавами тыңлаулар процедурасын үтәргә тиеш.

Район контроль-хисап палатасы 1 декабрьгә кадәр бюджет турында карар проекты хакында, әлеге проектның ачыклаган очракта җитешсезлекләрен күрсәтеп, бәяләмә әзерли.

Район Советы депутатларын район бюджеты турындагы карар проектына төзәтмәләр әзерләгәндә Районның Контроль-хисап палатасы бәяләмәсе исәпкә алына.

Чираттагы финанс елына һәм план чорына район бюджеты турында карарның кертелгән проекты районның Контроль-хисап палатасы бәяләмәсе белән комиссиягә, шулай ук район Советы депутатларына карауга җибәрелә.

Район бюджеты турында карар проекты буенча килешмәгән мәсьәләләр килеп чыкса, район Башлыгы карары белән килешү комиссиясе төзелергә мөмкин, аңа район Башкарма комитеты һәм район Советы вәкилләренең тигез саны керә.

Килештерү комиссиясе Район Башлыгы тарафыннан расланган регламент нигезендә район бюджеты турында карар проекты буенча бәхәсле мәсьәләләрне карый.

Район Советы кабул иткән чираттагы финанс елына һәм план чорына бюджет турындагы карар бер тәүлек эчендә имзалану һәм рәсми бастырып чыгару өчен җибәрелә.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башлыгы, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советы Рәисе М.Р. Гафаров